Sabira Stahlberg

# Filip köymädä



## Sabira Stahlberg

# Filip köymädä

**Fazile Nasretdin tärcemäse**
**Maria Viitasalo räsemnäre**

Helsinki 2022

*Tampere tatar cämiyätenä (Tampereen tataariseurakunta, per. 1943), Finlandiya İslam Cemaatinä (Suomen Islam-seurakunta, per. 1925) häm Oskar Öflund vakıfına matdi yärdämnäre öçen samimi rahmätlärebez.*

OSKAR ÖFLUNDS STIFTELSE

**Ciñel tel däräcäläre**
**Däräcä 1: İñ ciñel**
Däräcä 2: Ciñelräk
Däräcä 3: Ciñel

Tatar, 2. basma / edition
Şved telendä / Original: *Filip på båten*
Tärcemä: Fazile Nasretdin
Eş törkeme: Albina Samarhan, Kamer Yafay Nogmanov, Derya Samaletdin, Adile Samaletdin, Nergis Samaletdin, Liliä Däülät

© Sabira Stahlberg 2022
© Fazile Nasretdin, tärcemä / translation 2022
© Maria Viitasalo, räsemnär / illustrations 2022

Bokpil ▸ bokpil.eu
Aybagar ▸ aybagar.eu
Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-34-8 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-35-5 (E-kitap, PDF)

# Bülem 1

Minem isemem Filip.
Bügen minem tugan könem.
Min tort yaratam.
Äniyem ber zur tort peşerde.
Anıñ öste küpertelgän kaymak
häm bakça ciläkläre
belän bizälgän.

Tort östendä keçkenä şämnär.
Alarnı miña tizdän kabızırga yarıy.
Kabızgaç, alarnı örep sünderäm.
Örgändä üzemä teläk telärgä yarıy.

Min … telimmm.
Yuk, äytmim!
Aldan äytergä yaramıy bit.

Bügen minem zur bäyräm könem.
Böten näsel kunakka çakırılgan.
Barısı da östäl artında
tezelep utırgannar,
söyläşep toralar.

Äbä belän babay divanda utıralar.
Äti kunaklarga kahvä kaynata.

‒ Filip, kuzinnarıñ belän söyläş,
äni äytä.
Minem kuzinnarım bişäü.
Barı tik kızlar.
Alar mine kızıksındırmıy.
Närsä äytim soñ?

Alar atlar yaratalar.
Atlar turında gına söyläşälär.
Alardan at ise dä kilä.
Uf, min atlardan ciränäm.
Minemçä, iñ cirängeç is ‒ at ise.
Kuzinnarım belän söyläşergä telämim.

Min äbäy belän söyläşergä telim.
‒ Äbäy tizdän kiler.
Träne soñga kalgan, äti äytä.

Min äbäyne yaratam.
Ul mine añlıy.
Äbäy berkayçan
da açulanmıy.
Ämma kayda tora ikän?
İşek kıñgıravı şaltırıy.
Äbäy kilä!

‒ Äydägez, äle tort aşıybız,
äni çakıra.

– Filip, tortnıñ
şämnären kabız, äti äytä.
Şırpı tartmasın alıp kiläm dä,
şämnärne kabızam.
– Oy, nindi matur şämnär!
äbäy äytä.
– Örep sünder!
Nindi dä bulsa teläk telä!



# Bülem 2

Tirän genä sulış alam,
üpkämne hava belän tutıram da,
şämnärgä öräm.
Öf!
Şämnär barısı da beryulı sünä,
– Bravo, dip kardäşlär
kıçkırıp cibärälär dä,
kul çabalar.

Äni tortnı kisä.
Berençe kisägen miña birä.
– Filip, tugan köneñ
kotlı bulsın, äti äytä.
– Nu, Filip, närsä telär ideñ? äbä sorıy.
– At? Dinä kuzinım täklif itä.

Barısı da kölälär.
Bitem kızara.
– Äytep karasam yarıymı? äni sorıy.
– Uyın. Komputer uyını!
– Yuk, cavap biräm.
– Minem citärlek küp
uyınnarım bar inde.
– Äyt inde, Filip, Bibinur apa
kıçkırıp cibärä.

Bolay bezgä tort eläkmi!
– Et balası, äytep kuyam.
– Min et telim.
– Niçek alay inde, Filip,
äni borçılıp äytä.

– Sin beläseñ bit, minem
allergiyäm bar, äti äytä.
Bez et ala almıybız.
– Ämma min et telim,
üzsüzlelänep äytäm.

Äti başın çaykıy.
– Alay bulmıy inde, Filip.
Siña añlarga kiräk.
Minem yakınımda etlär bulsa,
halem naçaraya, äti äytä.

– Filip, işetäseñme, äbäy äytä.
– Säyähatkä çıksak.
Yaratır ideñme?
– Säyähatkä? Kaya?
dip aptırap kalam.

– Sin dä min ikäü.
Köymä belän säyähatkä çıksak,
äbäy cavap birä.
– Döres işettemme ikän?

– Çınnan da mı?
Köymä belän?
kıçkırıp cibäräm.

– Çınnan da, äbäy äytä,
irtägä uzgaç yulga çıgabız.
– Uraa, kıçkırıp cibäräm.
– Äni! Äti!
Min köymä belän kitäm!

Äbäyne koçaklıym.
– Sin dönyanıñ iñ yahşı äbäye,
dip äytäm.

Äbäy kölä.
– Min yäşel çäy häm
ber zur gına kisäk tort
telär idem, äytä.

# Bülem 3

Min äle äbäy belän köymädä.
Döresen äytkändä, bu vapur.
Vapur köymädän zurrak.

Alay bulsa da, köymä diyälär.
Nigä ikän şulay?
Anısın çınlap ta belmim.

Köymä dönya kadärle zur.
Koridorları bik ozın, küpkatlı.
Katları dek dip atala.
Häryakta halık.
Ber-berlärenä tavışlap endäşälär.
Arı-bire koridorlarda yörenälär.
Beräüläre zur çantalar kütärgän.
Härberse üz kayutasın ezli.

– Köymädäge bülmälär kayuta
dip atala, äbäy äytä.

Bez dä üz kayutabıznı ezlibez.
Anı tabu ciñel eş tügel.
Divardagı numırlarga karap barabız.
Ber koridorga keräbez dä,
sulga borılabız.

Annarı uñga äylänäbez,
läkin kayutabız anda tügel.
– Bu köymä ber labirint,
äbäy pufıldap äytä.
– Kayutabıznı tabarbızmı ikän,
ni uylıysıñ?
Tagın da uñga borılabız.

– Nihayät! äbäy tınıçlanıp äytä.
Tegendä.
Kayuta numırı 7258.
İşekneñ bigen açıp
kayutabızga keräbez.
Ul baytak keçkenä.
Kayutada ike yatak
häm yuınu bülmäse.

– Min östäge yatakta
yoklarga telim, äytäm.
– Yarar, min bik riza,
äbäy äytä.

Çantalarıbıznı idängä kuyabız.
– Äydä, yugarı dekkä barıyk,
äbäy äytä.
– Anda köymäneñ limannan
çıkkanın kürä alabız.
Dürbüneñne onıtma.

Binoklne äti miña tugan kön
büläge itep birgän ide.
Ul yaña häm bik açık kürsätä.
Dürbünne savıtınnan çıgaram da,
muyınıma asam.

Lift belän unınçı dekkä menäbez.

Annan tışka, köymäneñ
yan-yagındagı dekkä çıgabız.
Anda halık şıgırım tulı.

Härberse köymäneñ limannan
çıkkanın kürergä teli.
Dürbünem belän
diñgezgä karıym.

Oy! Diñgez tıp-tın.

# Bülem 4

Diñgez adättä yäşel yäki
zäñgär töstä bula.
Läkin bügen altın kebek yaltırıy.
– Koyaş tübändä, äbäy añlata.
– Ul kük yözen sarıga buyıy da,
kükneñ töse diñgezdä çagıla.
– Matur, äytäm.
– Äle kitäbez,
äbäy kıçkırıp ala.
– Dürbüneñne tot.

Köymäneñ motorları
dañgır-doñgır itä.
Böten köymä selkenä.
Annarı äkren genä şuıp
limannan ayırıla.
Dürbün belän karıym.
Ber atauda mayak küräm.
Mayak ak, utı kabına da sünä.

– Äbäy, bak, mayak, kıçkırıp cibäräm.
– Bir, karıym.
Dürbünne äbäygä suzam.
Ul da mayakka karıy.
– Oy nindi matur, äbäy soklanıp äytä.

– Tegendä närsä?
Cilkänle köymälär.
Sigez... tugız... yuk,
unike cilkänle köymä, äbäy sanıy.
– Kaya? Bir, min dä karıym,
kızıgıp sorıym.

Äbäy dürbünne miña suza.
– Undürt cilkänle köymä,
sanap kuyam.
– Çınnan da mı? äbäy sorıy.
– Alay bulsa, min döres sanamadım.
Bez cilkänle köymälärgä ozak karap torabız.

İskärmästän äbäy äytä:
– Filip, öşiseñme?
Diñgezdän salkın cil örä.
– Yuk, cavap biräm.
– Öşemim.
Yon külmägem yahşı cılıta.

Yon külmäkne äni miña
tugan kön büläge itep birgän ide.
Ul anı üze bäylägän.
Yon külmäk zur häm kalın.
Ak belän zäñgär sızıkları bar.
Çınnan da cılı.
Ämma äbäy öşi.

Östendä yuka külmäk kenä.
– Min yon külmägemne kiyep kiläm,
äbäy äytä.
– Minem belän barasıñmı
yäki teläbräk monda kötäseñme?
– Min sine monda kötäm, cavap biräm.
– Cilkänle köymälär kararga telim.

– Min şunnan uk kaytam, äbäy äytä.
– Dürbüneñne diñgezgä töşermä.
– Tiz genä kayt,
äytäm.
– Açıga başladım.
– Min kaytkaç aşarbız,
äbäy äytä.
– Pizza niçek bulır?
– Bik tä tämle bulır, cavap biräm.

Äbäy kayutaga kitä dä,
min cilkänle köymälär kararga kalam.

Alar tın gına diñgezdä şuıp yözälär.
Zur akkoşlar kebek.
Şundıy maturlar!

# Bülem 5

Kinät arkam artında
ällä nindi tavış işetelä.
Närsäder tırnap tora.
Tirä-yagıma karıym.
Dek bup-buş.
Min dektä yapa-yalgız.

Halık yuk bulgan.
Restorannarda utıralardır
yäki kibetlärdä äyberlär
satıp alalardır.

Tagın tırnıy.
Närsä ikän?
Tirä-yagıma centekläp karap çıgam.
Tıñlıym, läkin tıp-tın.

Äle tagın tırnıy.
Tavış zur sandıktan kilä.
Divar yanında ber yäşel sandık tora.

Sandık yanına baram.
Östendä nider yazılgan.
– Kotkaru jiletları, ukıp çıgaram.
Tukta! Jiletlar şıgırdamıy bit.

Närsä ikän?
Kemder yäki närsäder sandık eçendä.
Anda anı yabıp kuygannar.
Kapkaçın açarga tırışam,
läkin sandık biklängän.
Päkem kayda ikän?
Kesäläremdä kazınam,
läkin päkemne tapmıym.

Äy inde! Päke bişmätemneñ kesäsendä,
bilgele, ä bişmätem kayutada.

Tagın tırnıy.
Sandık artına küz salam.
Äle anı küräm.
Keçkenä et. Aklı-köränlre et balası.
Kolakları ozın, küzläre tabak tikle.
Şıñşıy da, mine kürä.

İsem-akılım kitep etne küzätäm.
‒ Sälam siña, äytäm.
Et kaçarga tırışa.
Minnän kurka kebek.
‒ Monda niçek eläkteñ? sorıym.
Ul sandıknı algı täpiläre belän tırnıy.
‒ Sandık artında sin
nişläp yatasıñ? süzemne davam itäm.
‒ Tilerdeñme?

# Bülem 6

Et kuzgalmıy da.
Mine dikkat belän tıñlıy.
Zur, kara küzläre belän miña karap tora.
Miña kalsa, et baytak küñelsez kebek.
– Mesken keçerük, äytäm.
Berüzeñ genä me?

Tirä-yagıma karıym.
Berkem kürenmi.
– Hucañ kayda? sorıym.
– Kaçtıñmı yäki hucañnı da,
ännäñne dä yugalttıñmı?
Alar sine ezlilärder.

Hucañnı tabarga kiräk.
Ämma niçek?
Beraz uylıym.
Älbättä!
Bik ciñel eş.
Här etneñ muyınında muyınçak bar.
Anda adrese dä bar.

Läkin etne niçek çıgarıym?
– Äydä akıllım, çık, dip äydim.
– Akıllım!

Sandık östenä tezlänäm dä, kulımnı suzam.

– Çık, dip çakıram.
– Hucaññı ezlibez.

Et, älbättä, telämi.
Eçkäräk kaça da, urınında
utırgan kileş çinıy.

– Çık annan, äytäm.
– Kurıkma. Siña bulışırga telim.

Et alay bulsa da kuzgalmıy.
– Min kurkınıç tügel, añlatam.
– Min akıllı, bik akıllı.
Kesämdä karamel dä bar.

Ber karamel çıgaram da,
etkä kürsätäm.
– Menä siña beraz tatlı, äytäm.

Et utırgan urınında
karamelne isnäp ala.
Yöräkne özep çinıy başlıy.

– Äydä inde, min
sabırsızlanıp kıçkıram.
– Yuksa sine kütärep çıgaram.

Sandık östenä korsagım
belän yatam da,
kulımnı suzam.
– Äle siña tıñlauçan bulırga kiräk,
äytäm.
– Miña, Filipkä kil.

Etkä totınıp karıym.
Ul yomşak häm cılı.
Sabır gına utıra da kötä.
Min anı kütärep alam.

– Sin bik avır,
sulış alıp äytäm.
– Sine köçkä kütärä alam.

Ul vou dip şat örä dä,
kulımnı yalıy.

# Bülem 7

Etne koçaklap sandık östenä utıram.
– Sin nindi täti, diyäm.
Etne koçaklıym.
– Min dä mondıy et telär idem.
Bik söykemle.

Ämma et kaltırıy.
Kurkadır, bälki öşi dä.
– Öşiseñme? sorıym.
– Mesken keçkenä vov-vov!
Etne koçaklıym.
Ul kaltıranıp borının yon
külmägemneñ eçenä tıga.
– Bik inde ozın kolaklarıñ,
etkä äytäm.

Etneñ kolakları çınnan da ozın.
Algı täpilären häm
başın bergä sanasañ,
kolakları ozınrak.
Berkayçan da mondıy
ozın kolaklı et kürgänem yuk ide.

Döresen äytkändä, mondıy
et tä äüväl kürgänem yuk ide.

Keçkenä, kıska ayakları,
keçkenä koyrıgı.
Yöze böreşkän.
Küzläre kuyı kara-körän,
kara dip äytep bula.
Tokımı ni ikän,
uylanıp toram?
Ozın kolaklı, yöze böreşkän.

Aklı-köränle tunı…
Äle beldem!
Ul basset.
Bassetlarnı räsemnärdä kürgänem bar.
Döresen äytkändä,
et iskitkeç yämsez,
läkin ber ük vakıtta söykemle dä.
Tagın koçaklıym.

Ul borının miña taba bora da,
bitemne yalıy.
Bötenläy yüeşlänäm.
– Oy, teleñ bik kıtırşı, kölep cibäräm.
– Vou, dip örä.

Uynap kına mine
teşlärgä tırışa.
Teşläre älegä keçkenä,
söt teşläre.

Etlärneñ yäşe turında
ukıganım bar.
Bu et balası berniçä aylık.

– İsemeñ niçek? sorıym.
Et koyrıgın selketä.
Kaygılı küzläre belän
miña karıy.

Älbättä, cavap birä almıy.
Annarı muyınçak
isemä töşä.
Muyın bavı!
Etneñ muyının kapşıym.

Muyınçagı yuk.



# Bülem 8

Säyer.
Etlärneñ muyınçagı bulırga tiyeş.
Anda adres häm telefon numırı bula.
– Sineñ muyınçagıñ kayda? sorıym.

Et koyrıgın selketä genä.
Kulımnı teşlärgä tırışa.
Ozak uylanıp toram.
Äle nişlim?

Etneñ iseme dä yuk,
adrese dä yuk.
İyäse köymädä bulırga tiyeş.
Ämma kayda?

Min etkä karıym.
Ul miña baga.
Mine yarata,
min dä anı bik yaratam.

– Sineñ isemeñ Basse bulsın,
karar kılam.
Bik kızık isem.
Miña kalsa, siña kileşä dä.
Basse borının kultıgıma tıga.

Tagın kaltırana.
Ul öşi.
Min dä öşim.
Diñgezdän boz kebek salkın cil isä.
Bassene koçagıma kütäräm.

‒ Äydä, eçkä keräbez.
Eçtä cılırak, äytäm.
Eçtä yaktı häm cılı.

Bassenı koçagımda totam.
Borınıma aş ise bärelä.
Avızıma sular kilä.

Oy, bik açıkkanmın ikän!

Kinättän äbäy isemä töşä.
Ul soñ kayda?
Kayutabız yırakta tügel bit.
Äbäygä monda bulırga
kiräk ide inde.

Min ber eskämiyägä utıram.
Bassenı koçagımda totam.
Ul başta idängä sikerergä tırışa.
Annarı kultıgıma kerä.
Yokısı kilä dä, avızın aça,
küzlären yoma.

Artık kaltıramıy.
Min utırıp äbäyne kötäm.
Kötkändä Basseniñ
kolak artın häm
arkasın kaşıp toram.

Ul tınıç kına sulış ala da,
koçagımda bik tiz yokıga kitä.
Kolagına totınıp karıym.
Kolagı kıymıldap kitä,
ämma Basse uyanmıy.

Ul tirän yokıda.

# Bülem 9

Telefonım şaltırıy.
Äbäy şaltırata.
– Hey Filip, haleñ niçek? äbäy sorıy.
– Yahşı, äytäm.
– Sin kayda?

– Kayutada, äbäy äytä.
– Kilgändä ber tanışıma oçradım.
Baytak ozak söyläştek.
Hallär niçek?
Barıp aşıykmı äle?

– Älbättä, äytäm.
Äbäy, beläseñme närsä?
Min ber…

Hı! Elemtä özelde.
Äbäygä şaltıratırga tırışam,
ämma ul cavap birmi.

Tagın tırışam. Cavap yuk.
Öçençe kat şaltıratam,
ämma äle dä cavap yuk.

Hazer nişlim?

Kayutabıznı tabarga kiräk.
Äbäy anda mine kötä.
Ä Basse belän nişlim?
Anı yalgız kaldıra almıym.
Yögerep tagın tışka çıgar da,
diñgezgä töşär.
Yäki kem dä bulsa anı taptap kitär.
Ul bit äldä näni et balası gına,
saklana belmi.

Bassenı üzem belän alıp barırga kiräk.
Äbäy iyäsen tabarga
miña yärdäm itär.
Bassenı kütärep kulıma alam.
Ul uyana da isni, avızın aça.
Annarı çinap ala.
Uyatkannı yaratmıy.

‒ Afu! Äbäyne barıp alırga kiräk,
äytäm.
‒ Anı tapkaç,
barıp aşarbız.
Min bik katı açıktım,
sin dä açıkkansıñ.

Basse koyrıgın selketä dä,
täpilären cilkämä kuya.
Başta mırıldıy.

Annarı bitemne yalıy da,
kolagıma örä.

– Alay katı yaramıy, köläm.
– Kolagımnı avırttırasıñ bit!

Üzemne bik bähetle toyam.
Şul uk vakıtta üzemne
bähetsez dä his itäm.
Basse bik kıska vakıtka
gına minem etem.

Tizdän iyäsen oçratabız da,
etne birep cibärergä kiräk bula.
Hucası berkayçan da
tabılmasın ide,
böten yörägemnän telim.
Annarı Basse mindä
kalır ide dä,
mäñgegä mineke bulır ide.

# Bülem 10

Basse tirä-yagın küzätep tora.
Täpiläre belän cilkämä tayangan.
Ni bulgannarnı barısın da
kürergä teli.
Arada uzıp baruçılarga örä.
Min dä tirä-yagımnı küzätäm.

Liftlar kayda?
Lift belän kayutaga baralır idem,
läkin liftlar kayda, haterlämim.

Aldımda ber baskıç kına.
Baskıçtan äkren genä
aska taba töşäm.
Askı katta dek numır tugız.
Miña cidençe dekkä barırga kiräk.
Ul äldä ike kat astarak.

Karşıbızga ber törkem
kızlar kilälär.
Yanımda tuktıylar da,
şunda cıyılıp kalalar.

Miña hiç tä isläre kitmi,
Bassega soklangannar.

– Bik tatlı! berse kıçkırıp cibärä.
– Bik söykemle keçkenä vov-vov,
ikençese äytä.
– İnde matur maemay,
kızlar barısı da bertavıştan
kıçkırıp cibärä.

Basseniñ kolak artın häm dä
muyın astın kaşıp alalar.
Arkasın da kaşıylar.

Basse örä dä, koyrıgın selketä.
Ul kaşıgannı yarata.

– Bu sinekeme?
kızlardan berse sorıy.
Cavap birmim.
Kızarınam da kolaklarım kaynarlana.
– Sin nindi bähetle, kız
könlägändäy äytä dä, sulap ala.
Ul Bassenı bik ozak kaşıp tora.

– Min et balası telär idem,
äniyem anı karıy
almam dip uylıy.
Kız tagın sulap ala.
Annarı kızlar yögerep
üz yullarına kitälär.

Baskıç basmasına utıram.
– Minem etem bulsa ideñ,
Bassega äytäm.
Bik telär idem.
Çınnan da telär idem.

Bassenı katı koçaklıym da,
ul çinıy.
Dürbünne häm dürbün
bavın kimerä başlıy.

– Tukta, köläm.
– Bavın çäynämä, özeler.
– Vov, vov, Basse örä.

Kölgän kebek bula.
– Äle bezgä äbäyne
ezlärgä kiräk, äytäm.

# Bülem 11

Ayagürä toram da,
Bassenı kütärep cidençe dekkä töşäm.
Bezneñ kayutabız biredä bulırga tiyeş.
Kayutada äbäy mine kötä.
Ämma kayuta kayda?

Ber koridorga keräm.
Uñ yakta işeklär küp, sul yakta da bar.
İşeklärdäge numırlar
hämmäse cide belän başlana.
Berse dä cide häm ike belän başlanmıy.

Basse başın cilkämä kuya.
Mine ul tınıçlandıra.
İkençe koridorga äylänep keräm.
Anda da cide belän ike yuk.

Ber zäñgär uniformalı apa karşıma kilä dä:
– Siña yärdäm itä alammı?
Kemne bulsa ezliseñme, soraşa.
– Min kayuta numır 7258 ne ezlim,
cavap biräm.
– Kiläse koridorga bar da, uñga borıl.
Annarı turı alga bar da, sulga äylän,
apa äytä.

– Rahmät, äytäm.
– Baytak avır, ämma kayutanı tabarmın inde.

Yandagı koridorga keräm dä,
uñga borılam.
Annarı turı alga taba baram.
Ämma yandagı koridorda
sulga iltä torgan yul yuk.

Uñga äylänäm. Bälki apa uñga dide?
Läkin anda kayutalar yuk,
yalgız ber şkaf kına.
Yalgış añlaganmın.

Tege apa belän oçraşkan urınga
kire kaytırga telim.
Läkin äle inde anı tapmıym,
sorarga da kem dä yuk.
Berkem dä koridorda kürenmi.
Häryak tıp-tın.

Äbäygä şaltıratırga tırışam,
ämma ul cavap birmi.
Ber divarga söyäläm.
Et taptım da, äbäyne yugalttım.
Koridornı taptım da,
kayutanı yugalttım.
Äle nişlim?

# Bülem 12

Basse borınımnı yalıy.
Ul mine yuatırga teli.
‒ Sin akıllı, äytäm.
‒ Äbäyne niçek tabarbız?

Tämam şul vakıtta
tavış yañgıratkıçınnan belgertälär:
‒ Kamil, infoga kil.
Kärimä sine kötä.
Kamil, sine kötäbez.
İnfoga kil, yañgıratkıçtan kabatlıylar.

Başımda ber fiker tua.
Min infobüroga bara alam bit!
Annan äbäygä kıçkırta alam.
Äbäy, älbättä, kayutabızda
yañgıratkıç tavışın işetä.

Dimäk, miña koridorlar buylap
kayutabıznı ezlärgä kiräkmi.
İnfobüronı gına tabarga kiräk.

Anda aşıgam. Bassenı
koçagımda totıp,
koridor buylap yögeräm.

Kinät min liftlar yanında.
Anda harita bar.
Haritanı ukıym.
Ähä!
İnfo dürtençe dektä.
Liftka keräm.
Lift dürtençe dekkä iltä.
Şatlanam.

Tizdän äbäyne tabam inde!
İnfobüroga yögeräm.
Anda östäl artında ber kız utıra.
Ul telefonnan söyläşä.
Söyläven beterä,
läkin telefon tagın şaltırıy.

Östäl yanına baram.
Östäl yanında ber ir keşe basıp tora.
Açulıga ohşıy.
Kız miña dikkat itmi.
Äle ikençe telefon şaltırıy.

Kız ike telefonda da
ber ük vakıtta söyläşä.
Äle telefonnarnıñ bersen yaba.
Annarı ir belän söyläşep ala.
İr kıçkıra, kulların selketä.
Kız ikençe telefonın da yaba.

– Afu itegez, kızga äytäm.
– Min…
– Üz räteñne kötärgä kiräk,
ir açulanıp kıçkıra.
– Ämma… äytäm.
– Äbäyemne yugalttım.

– Ber minut, kız äytä.
– Tegendä eskämiyägä
barıp utır da köt.

Östäl yakınındagı
eskämiyäne kürsätä.
Utıram da kötäm.

Kayçan bulsa da miña
vakıtı bulır mikän?

# Bülem 13

Äbäygä tagın şaltıratıp karıym,
ämma telefon eşlämi.
Bataryası betä dä,
telefon ülä. Haman da şulay!

Kötäm dä kötäm.
Telefonnı tagın açam, äle eşli.
Beraz köçe kalgan.
Äbäygä şaltıratıp karıym,
läkin telefon sünä.

Östäl artındagı kıznıñ miña vakıtı yuk.
İr kıçkıra da orışa.
Kızga yärdäm sorarga turı kilä.

İke uniformalı ir keşe info östäle yanına kilä.
Orışuçı ir belän söyläşälär,
läkin ul ulavın dävam itä.

Äle miña uylarga kiräk.
Basse dürbün bavın çäyni.
Dürbünne dä kimerergä tırışa,
ämma ul artık katı.
Annarı külmägemdäge töymäne
kimerä başlıy.

Basseniñ selägäye bik aga
da, külmägem yüeşlänä.
Uylıym da uylıym.

Äbäyne ezlärgä kiräk,
ämma kayutanı taba almıym.
İnfobüroniñ da miña
bernindi dä yärdäme yuk,
telefon da eşlämi.

Äbäy mine ezli.
Bälki östäge dekkä barır?
Min anda kötärgä buldım bit.
Dimäk, ul dekkä
kire kaytırga kiräk.

– İşetäseñme Basse, äytäm.
– Tukta, külmägemne
çäynämä, yararmı akıllım.
Yahşı et, yuk, teşlämä!
Äbäy tışkı dektä,
mine ezli.

Basse başın kırın
kuya da, koyrıgın selketä.
– Alaysa äydä, dip äytäm.
– Äbäy östäge dektä.
Anı beläm, şik tä yuk.

# Bülem 14

Liftlarga taba baram,
ämma ällä kaya adaşam.
Liftlarnı tapmıym.
Kinät min ber kiñ koridorda.
Anda kibetlär bar häm dä keşe küp.

Berençe kibet huşbuylar sata.
Kibettän köçle huş islär añkıp tora.
Töçkeräm, Basse da töçkerä.
Min añardan köläm.
Töçkergändä anıñ kolakları cilferdi.
Borının da böreşterä.
Bik kölkegä ohşıy.

Şunda bezne ike apa uzıp kitä.
– Tfu! dip berse kıçkırıp cibärä.
Et. Fu!
Köymägä koçık kiterergä yarıymı?
Tıyarga kiräk ide.
– Mesken et, ikençese äytä.
– Köymädä torırga yaratmıydır da ul.

– Eteñne öydä kaldırırga ide,
berençese äytä.
– Anı köymägä alıp kilmäskä ide.

Etlär säyähat itärgä yaratmıylar.
Et balaları bigräk tä näzek.
– Bu mineke tügel, cavap biräm.
– Min anı taptım, dip añlatam.
– Äye, äye, apa äytä.
– Ni äytkänemne onıtma.
Kiläçäk märtäbä etne öydä kaldır.
– Yarıy, dip yämle genä
baş iyep äytäm.

Apalar yulların dävam itälär.
Min ikençe yakka taba kitäm.
Anda çantalar häm şarflar
sata torgan kibet.
Anıñ yanında rizık kibete.
Dönya kadärle açıktım.

Bassega da aşamlık
alırga kiräk bulır ide.
Kesäläremne kapşanam da,
beraz vak akça tabam.
Ni bulsa tatlı alırga citär inde.

Et rizıgı kibettä bar mikän?
Kibetkä keräm digändä,
uniformalı ir mine tuktata.
– Kibetkä etlär kertärgä yaramıy,
kisätep kuya.

– Basse et balası gına äldä, äytäm.
– Näni et.
Anı miña koçakta totarga kiräk.
Totmasam, kaçıp kitä, añlatam.

– Kibetkä etlär kertärgä yaramıy,
sakçı açulanıp kabatlıy.
Tup-turı aldıma kilep basa.
Söykemsezgä ohşıy.
Äylänäm dä kire borılıp kitäm.



# Bülem 15

Yılıysım kilä.
Küz yäşemne sörtep alam.
Nigä barısı da Bassega bäylänä?
Etlär yaratmıylar mikän?

Basse berkayçan da berkemne dä
avırttırırga telämi.
Beraz teşli genä,
çönki teş urtları kıçıta.
Äle anıñ söt teşläre töşärgä tora da,
annarı it teşläre çıga.
Şuña kurä ul kurkınıç tügel.

Ber kibetneñ divarında belderü taktası.
Belderü taktasında
kızıl tügäräk eçendä et räseme.
Anda da etlär kertärgä yaramıy.

Koridornıñ ikençe oçında baskıç.
Nihayät. Baskıçtan menä başlıym.
Basse kulımda bik avır toyıla.
Hazer yal itärgä turı kilä.
Baskıç basmasına utıram.
Biredä keşe dä yuk,
berkem mine borçımıy.

Telefonnı kesädän çıgaram.
Äle tagın eşli.
Añlap citep bulmıy.
Kayçak eşli, annarı tagın eşlämi.
Äbäygä şaltıratıp karıym,
läkin ul cavap birmi.
Telefon şaltırıy da şaltırıy.
Tagın şaltıratam.
Cavap yuk.
Annarı telefon sünä.

Basse tınıçsız kıymıldana.
Borıla da, äylänä,
koyrıgın selketä.
Zur küzläre belän miña karıy.

Kinät kulımnan kotıla.
Sikerep idängä töşä dä,
yanımda utırıp kala.
Utırgan cirennän torganda
keläm östendä yüeş ez kala.

Basse örä dä kaçıp kitä.
Tämam şul vakıtta
äbäy şaltırata.

‒ Aloo, Filip, sin kayda?
äbäy telefonda kıçkıra.

# Bülem 16

– Basse kaça! äbäygä kıçkıram.
Telefon sünä.

Telefonnı tiz-tiz kesämä salam da,
Basse artınnan atılam.
Ul katı yögerä.
Kolakları kanatlar kebek kagıla.
Hazer oçıp kitä!

Ämma Basse oçmıy.
Bigräk tiz yögerä.
Kıska täpiläre idändä
tıpır-tıpır itä.
Koyrıgı tup-turı ürä tora.
Min köçemnän kilgän kadär
tiz yögeräm, ämma anı tota almıym.

Oy! Dürbün bavı ıçkına.
Basse anı teşläp özgän.
Dürbün kulımnan töşä.
Bähetemä çak kına totıp ölgeräm.

Dürbünne kulımda totam da yögeräm.
Basse ber koridorga äylänep kerä.
Annarı ikençegä borıla.

Uñga atıla, annarı sulga.
Köt, dip pufıldap äytäm.
– Tukta! Basse!

Basseníñ miña ise dä kitmi.
Biyek baskıçtan şat kına
sikerä-sikerä töşä.
Yärdäm! Yıgılıp töşär!
Baskıç berkayçan da betmi.
Yuk, äle bette!

Basse ber ozın koridorga
yögerep kerä.
Annarı tagın baskıçtan
aska taba sikerep bara.
Basmaları niçä ikän, belmim.
Min yögeräm genä.

Basse äle ikençe koridorga
borılıp kerä.
Min artınnan atılam.

Nihayät! Koridor betä.
Basse yıragrakka yögerä almıy.
Şöker, koridorda ber genä işek,
ul da biklängän.

– Äle totıldıñ, Bassega kıçkıram.

# Bülem 17

Kinät Basse tuktıy.
Kire yögerep kitärgä tırışa,
läkin min anı totam,
katı gına totıp toram.

Ul koçagımda kauşana.
Yögerergä genä teli.
Ämma min yögergänen telämim.

‒ Ahmak et.
Kaya barasıñ? sorıym.
‒ Kaçıp kitmäsäñ, äybäträk.
Anı sin belergä tiyeş.

Şunda äbäy isemä töşä.
Dürbünne kulımnan
saklanıp kına kuyam.
Ber kulım belän telefonnı
kesämnän çıgaram.
İkençe kulım belän Bassenı totam.

Telefon eşlämi.
Basse tagın kaçarga tırışa.
Ul yırtına da örä.
Kulımnı teşlärgä kereşä.

Anıñ teşläre bik ütken.
– Ay! Tınıçlan,
sabırsızlanıp kıçkıram.

Aldıbızdagı işekne açarga tırışam,
ämma ul biklängän.

Bez kayda ikän?
Monnan niçek çıga alabız?

İşektä autular dege dip yazılgan.
Bez kaydadır köymäneñ
iñ astagı katında.
Bötenläy yalgış kilgänbez.

Kire borılam.
Tışka çıgarga
ber genä yul bar.
Baskıç.
Öskä taba gına menep bula.

Bassenı ber kultıgıma,
dürbünne ikençesenä kıstıram.

Baskıçtan menä başlıym,
ämma Basse menärgä telämi.
Ul örä dä,
kulımnan kaçarga yırtına.

– Öskä menärgä kiräk, äytäm.
– Aska bara almıybız.
Anda asta su gına.
Östä äbäy häm rizık bar, añlatam.

Basse mırıldıy da örä.
Min anı koçaklıym.
– Tizdän ni bulsa aşarsıñ, ışandıram.
– Bik tä tiz.
Monnan çıgarga yul tabarga kiräk.



# Bülem 18

Baskıçtan menäm. Baskıç biyek.
Basse bik avır.
Mengän sayın avıraya bara.
Dürbün dä avır.

Bassenı kulımnan cibärä almıym,
ul annarı tagın kaça.
Cilkämä kütäräm dä,
ul sikerep töşärgä tırışa.

Miña anı ikekullap totarga kiräk.
Dürbünne dä berkaya da kuya almıym.
Oh!
Dürbünne kulımda totam da,
Bassenı koçaklıym.
Tir bora, arıy başlıym.

Nihayät, baskıç betä.
Ozın gına koridorga kiläbez.
Tup-turı alga taba baram.
Koridor kinät betä.
Uñ yakka taba ber yul açıla.
Häryakta işeklär,
ämma berkem dä yuk.
Bik katı arıdım, tuktarga kiräk.

İdängä utıram.
Köymäneñ koridorları çiksez küp.
Äbäy döres äytä. Köymä ber labirint.
Ber işekkä şakıldatıymmı ikän?
Bälki beräü miña yärdäm itär.
Tıñlap toram. Berkaydan da
ber tavış ta işetelmi.

Sägatemä karıym. Kiçke aş vakıtı.
Barısı da äle restoranda
kiçke aşların aşıylar.
Eçem avırta kebek,
çönki bik açıktım.
Aş turında uylasam, tagın da
kübräk açıgam.

Toram da yulımnı dävam itäm.
Bassenı koçagımda kütärep baram.
Küp-küp basmalar menäm,
niçä-niçä koridor ütäm.

Hazer inde hiç tä köçem kalmadı,
ämma monnan çıgu yulın tabarga kiräk.
Miña äbäyne yäki
infobüronı tabarga kiräk.
Yäki dä bezgä yärdäm itä ala
torgan beräüne.
Kemne genä?

# Bülem 19

Basse rähatsez.
Min anı koçagımda beraz
tirbätäm dä, ul tınıçlana.
Äkren atlap yulımnı dävam itäm.

Basse täpilären cilkämä kuya.
Başın täpiläre östenä sala da,
kolagımnı isnäp tora.
Kinät aş isen sizäm.

Basse başın kütärä.
Bez ber irken urınga kilep çıgabız.
Şunda restoran,
anıñ yanında kafe.

Katı susaganımnı sizäm.
Kafeda ni bulsa eçärgä alıp buladır.
Anda şirbät häm su bar.
Kesämnän vak akça çıgaram.

Ber ıstakan şirbätkä citä.
Barıp alam digändä, beräü yäş
ir miña taba kilä.
Zur buylı, sarı çäçle.
Östendä kara tişört.

Miña säyer karıy.
Bassega häm dürbüngä
tagın da säyerräk karıy.
Çat karşımda tuktıy.

– Karak, dip kıçkırıp cibärä.



# Bülem 20

Tänemne salkın basa.
İr kulları belän cilkämnän tota da,
mine selketä başlıy.

Annarı Basseni minnän tartıp alırga tırışa.
Basse därtlänep örä.
– Ay! Avırttıra, kıçkırıp cibäräm.
Kotılırga tırışam.
– Etne monda bir, ir ulıy.
Cilkämnän totıp mine selketä.
– Tukta! Cibär! kıçkıram.

Basseni totıp toram da, kitärgä tırışam.
Läkin ir minnän tizräk.
Belägemnän tota da tarta.
Bik katı kulımnı bögä,
dürbün kulımnan ıçkınıp idängä töşä.
– Etne monda bir! ir akıra.
– Dürbün! kıçkıram.
– Yaña dürbünemne vattıñ!
İr belägemnän totıp katı gına tarta.
– Yärdäm itegez, kıçkıram.

Kafedagı halık bezne küzätep tora.
Başta berkem dä kuzgalmıy.

Annarı beräüläre tora da,
bezneñ yanıbızga kilä.
İrgä mine cibärergä kuşalar.

Läkin ir mine katı tota.
Yöze häm muyını kıp-kızıl.
– Bu malay kız dustımnıñ
eten urlagan, dip katı kıçkıra.
– Min anı urlamadım, karşı kuyam.
Yılıy başlıym.
– Yaramas bala, ir kıçkıra.

Tagın da Bassenı minnän alırga tırışa.
Basse örä dä, irneñ kulın teşli.
– Afärin et, pışıldıym.
– Ay! ir kıçırıp cibärä. – Tile et!

– Tınıçlanıgız, ber abıy äytä.
– Äle bu eşne tikşeräbez.
Malaynı cibär.
Abıy irneñ belägennän katı gına tota.
İr mine cibärä,
ämma miña yämsez baga.
Avır sulap ala.
Basse aña örep tora.
Min dürbünne idännän kütäräm.
– Añlat äle, abıy äytä.
– Närsä buldı?

# Bülem 21

– Kız dustımnıñ ete bar, ir äytä.
Basset balası.
Bez tışkı dektä bulganda,
ul kaçıp kitte.
Bez anı häryakta ezläp yördek.

– Kız dustıñ kayda, ber apa sorıy.
– Ul eten ezläp yöri, ir cavap birä.
– Alay ikän, apa äytä.
– Ä bu malay?

Apa yahşı keşegä ohşıy.
Ul minem halemne añlıy şikelle.
Küz yäşläremne sörtep alam.
Basse tınıçlana.
Täpilären cilkämä kuya,
kolagıma çinıy, bitemne yalap ala.

– Etne tışkı dektä taptım,
borın astınnan gına cavap kaytaram.
İnfobüroga da bardım.
Miña kemneñ dä ise kitmäde.
Min äbäyemne ezlim.

– Alay ikän, apa äytä.

– Minemçä mäsäläne bolay çişik.
Sin kız dustıña şaltırat.
Ä sin äbäyeñä şaltırat.

Telefonnı kesämnän çıgaram.
Eşläsen ide inde,
dip ömetlänäm.
Äye, eşli.
Şöker.

– Filip, nihayät! äbäyneñ tavışı
telefonda yañgırıy.
– Sin kayda soñ?
– Kafe aldında, äytäm.
– Hazer uk monda kil.
Eş aşıgıç.

Äbäy añlıy.
– Min anda biş minuttan bulırmın,
dip ışandıra.
– Bar da yahşımı?
– Yuk, üksep cavap biräm.
– Monda krizis.
– Anı uzdırabız,
äbäy tınıç kına cavap birä.

# Bülem 22

Bik ozın bulıp toyılgan
cide minuttan yegerme sigez sekunttan
soñ äbäy kilep citä.
Min anı yögerep karşı alam.

– Ber-berebezne yugalttık,
dip kıçkırıp cibäräm.
– Kayutabıznı ezlädek, tapmadık.
Annarı Basse kaçıp kitte dä,
astagı katka autular degenä eläktek.
Dürbünem kulımnan
idängä töşte.
Vatıldı dip uylıym, añlatam.

– Kaygırma, dip äbäy süzemne bülä.
Kulyaulık birä dä, mine koçaklıy.
Şunnan uk halem ciñeläyep kitä.
– Basse kem? äbäy sorıy.
– Et, dip cavap biräm.
– Añladım, läkin bu keşelär kemnär?
– Et mineke, ir kıçkırıp äytä.
– Malay etne urladı.

Min Bassenı bik katı koçaklıym.
Ul ıñrana başlıy.

– Hiç tä ışanmıym, äbäy
kırt kisep äytä.
– Filip urlamıy.
Ul min belgän malaylardan
iñ tugrılıklısı.

Şul vakıtta kemder kıçkırıp cibärä.
Ber kız yanıma yögerep kilä dä,
Bassenı koçagımnan tartıp ala.
Min aptırap kalam.
Berni dä eşli almıym.
Küzemne kızga gına töbäp toram.



– Frida, kız kıçkırıp cibärä.
– Nihayät!
Sin kayda ideñ?
Täti karçıgım!
Min bik kaygırdım.

Basseniñ borının übä.
Basse örä.

# Bülem 23

– Alay ikän.
Etneñ iseme Frida ikän, äbäy äytä.
– Kem minem altınımnı taptı?
kız soraşa da, tirä-yagına bagına.
– Filip, äbäy äytä.
– Ul eteñne bik yahşı karagan.
Malay dustıñ Filiptän afu sorarga tiyeş.

– Rahmät, Filip akıllım,
kız kıçkırıp cibärä.
Bitemne übä. İke tapkır übä.
Bitem yüp-yüeş bula.
Cir yarılsa,
cir astına kerep kitär
idem dip his itäm.

– Filip sin iskitkeç!
Rahmät, rahmät,
kız kıçkıra da, Bassenı übä.
– Ä afu sorau?
äbäy sorıy.
– Ville, Filiptän afu sora,
kız äytä.

İrneñ iseme Ville ikän.

Anıñ yöze agara.
Borçılganga ohşıy.

– Afu Filip, dip mıgırdıy.
– Afu ütenäm.
Bik açulı idem.
Etebez kaçkaç, bik kurkındık.
Ville miña kulın suza.

– Ä dürbün? äbäy sorap kuya.

Ville dürbünne kulımnan ala.
Selketep karıy.
Här yagın tikşerep ala.

– Dürbün vatılmagan,
bavı gına özelgän, dip äytä.
– Basse anı çäynäp özde, äytäm.
– Vov, Basse şat kına örep cibärä.

– Frida matur et bit!
kız kıçkırıp cibärä.

Kız Basse-Fridanı übä.
Et tä kızniñ borının yalıy.

# Bülem 24

Kafeda halık yañadan
üz urınnarına kayta.

Bez kız, Ville, äbäy häm
min genä ayakta basıp kalabız.
Häm, älbättä, Basse-Frida.

Äbäy kızga citdi karıy.
– Siña eteñne yahşırak kararga kiräk.
Filip anı tışkı dektä tapkan dip
añlattı, äbäy äytä.

– Tışkı dektä!
kız kıçkırıp cibärä.
Minem mesken keçkenä Fridam!
– Eteñ kaçarga yarata,
min belgertäm.
– Ul yırakka, astagı autular
degenä kadär yögerep kaçıp kitte.

– Etneñ muyınçagı kayda? äbäy sorıy.
– Fridanıñ muyın bavı yuk.
Ul ansız söykemleräk,
kız cavap birä.
Kız etneñ borının übä.

Äle äbäy çınnan da açulana.
Yöze agarıp kitä.

– Et uyınçık tügel,
äbäy açulanıp äytä.
– Monı iseñdä tot!
Kıznıñ bitläre kızara,
läkin berni äytmi.
– Sau bulıgız, äbäy äytä.
– Filip, äydä!
– Basse, huş, sau bul, äytäm.

Etneñ başın kaşıp alam.
Basse-Frida koyrıgın selketä dä,
zur küzläre belän miña karıy.
Et kaygılıga ohşıy.
Min dä kaygılı.
Bik kaygılı.

Yörägem avır bulıp kitä.
Küzemdä yäşlär,
läkin kerfekläremne
yomgalap alarnı yuk itäm.

Äbäy kulın cilkämä kuya.
Pizzeriaga taba barabız.
Dürbünemne kulımda
kütärep baram.

Artta Basse-Fridanıñ
örgän tavışın işetäm.
Küptapkır yotkalagaç kına
tagın söyläşä alam.

– Bähetemä dürbünem
vatılmadı, äytäm.
– Yaña bau alırbız.

Äbäy kölep cibärä.
– Beläseñme, Filip,
äbäy äytä.
– Sin yugala beläseñ, läkin
äldä yahşırak tabıla beläseñ.

# Bülem 25

– Äbäy, äytäm.
– Basse minem etem
bulsa ide. Bik telär idem.

Äbäy citdi başın kagıp:
– Äye, min dä şunı telär idem, äytä.
– Sin anı yahşı karar ideñ.
Tege kız hiç tä et karıy belmi.
Niçek eten tıştagı dektä yugalta ala?

– Basse açıkkandır inde, uylanıp äytäm.

– Min dä, äbäy äytä
– Tuna balıklı pizza teliseñme?

– Älbättä, äytäm.
– Häm dä päinire küp bulsın!

**Filip äbäye belän köymä säyähatenä çıga.**



**Tışkı dektä et balası taba. Etneñ hucasın ezli, läkin anı tabu ciñel eş bulıp çıkmıy.**

**Äbäyen yugalta häm tizdän üze dä yulınnan adaşa. Et balası da kaçıp kitä...**

ciñel tel

978-952-7334-34-8

ISBN 978-952-7334-34-8 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-35-5 (E-kitap, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**